Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге Советы

КАРАР № VII

Күгәрчен ав. 2018 елның 19 сентябре

Референдум уздыру турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Күгәрчен авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күгәрчен авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Сорау буенча җирле референдум үткәрүне башлау:
" Сез 2018 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күгәрчен авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган балалардан 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:
- Күгәрчен авыл җирлегенә кергән авыл урамнарын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу һәм юлларны ремонтлау
- Күгәрчен авылында суүткәргечне ремонтлау, тузган торбаларны алыштыру.
- Күгәрчен авыл җирлеге территориясендә каты көнкүреш калдыклары чыгару өчен площадка ясау
- кышын авыл җирлеге территориясендәге юлларны карап торуга;
- су насосын сатып алу;

ЮК, ӘЙЕ,

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күгәрчен авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Күгәрчен авылы, Совет урамы 62А, Зангар-Күл авылы, Тукай урамы 3А адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы А.Т.Сафин